**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№479**
**26.01.2024**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кире кайтарырга ярамый торган урыннарны һәм хуҗасыз хайваннарны хуҗасыз хайваннарның элек яшәгән урыннарына кире кайтару турында карарлар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 6.1 өлеше, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кире кайтарырга ярамый торган урыннарны билгеләргә:

1) балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары, спортның актив төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар;

2) гомуми файдаланудагы территорияләр (мәйданнар, парклар, скверлар, массакүләм ял итү урыннары);

3) белем бирү оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары янәшәсендәге территорияләр;

4) мәдәният һәм сәнгать объектлары янәшәсендәге территорияләр;

5) җәмәгать туклануы оешмалары, сәүдә объектлары, шул исәптән стационар булмаган сәүдә объектлары янәшәсендәге территорияләр;

6) хайваннарны йөртү һәм өйрәтү өчен мәйданчыклар;

7) мондый йортларда урнашкан һәм аларга хезмәт күрсәтү һәм эксплуатацияләү өчен билгеләнгән объектлар, әлеге территорияләрне төзекләндерү элементлары, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары), тротуарлар белән күпфатирлы торак йортлар янәшәсендәге территорияләр;

8) зиратлар һәм мемориаль зоналар;

9) дини объектлар.

2. Хуҗасыз хайваннарны хуҗасыз хайваннарның элек яшәгән урыннарына кире кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгын билгеләргә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев